**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.10.2016 г.Казань № 01-02/265

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында аларны биләү коррупция куркынычлары белән бәйле булган вазыйфаларны биләүгә дәгъва итүче затларның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларның, шулай ук аларның ирләренең (хатыннарының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы мәгълүматларны бирүгә бәйле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының 2015 елның 11 мартындагы № 01-02/170 номерлы боерык белән расланган Исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында аларны биләү коррупция куркынычлары белән бәйле булган вазыйфаларны биләүгә дәгъва итүче затларның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларның, шулай ук аларның ирләренең (хатыннарының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы мәгълүматларны бирүгә бәйле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының 2015 елның 11 мартындагы № 01-02/170 номерлы боерык (2015 елның 22 декабрендәге № 01-02/821 номерлы боерык белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Исемлекне түбәндәге эчтәлектәге 5 һәм 6 пунктлар белән тулыландырырга:

“5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең “белгечләр” категориясендәге әйдәп баручы төркем вазыйфалары:

җирле үзидарә һәм муниципаль регистрны алып бару өлкәсендә норматив хокукый эшчәнлек бүлегенең әйдәп баручы советнигы;

җирле үзидарә өлкәсендә территориаль оештырылыш һәм контрольне гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәп баручы советнигы;

кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

мәгълүмат-аналитика эше, координацияләү һәм планлаштыру бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

җирле үзидарә һәм муниципаль регистрны алып бару өлкәсендә норматив хокукый эшчәнлек бүлегенең әйдәп баручы консультанты.

6. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең “тәэмин итүче белгечләр” категориясендәге әйдәп баручы төркем вазыйфалары:

җәмәгать судьялары эшчәнлеген тәэмин итү бүлегенең әйдәп баручы белгече;

мәгълүмат-аналитика эше, координацияләү һәм планлаштыру бүлегенең әйдәп баручы белгече.”.

2. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлегенә (Сафин А.Г.) әлеге Боерыкны “Интернет” телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталындагы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы сайтының “Коррупциягә каршы тору” бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз карамагымда калдырам.

Министр Л.Ю.Глухова